**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ЛАИШЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЛАЕШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

Чернышевского ул., д.23, г.Лаишево 422610

Чернышевский урамы, 23 нче йорт Лаеш ш. 422610

Тел: 8-(84378) -2-52-28 Факс: 8-(84378) -2-54-34

e-mail: Ispolkom.Laishevo@tatar.ru

---

2023 елның 06 июле 2154 номер

# КАРАР

**«Татарстан Республикасы, Лаеш муниципаль районы, Матюшино авыл җирлеге, «Наратлык» ПК, 7, 31А,10,26 йорт адресы буенча җир участоклары чикләренә кадәр газүткәргеч тармагы»территориясен планлаштыру проектын әзерләү турында**

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 41, 42, 45 статьяларына, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында " 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль Законына, планлаштырылган структура элементларын бүлеп бирү, гомуми файдалану территорияләре чикләрен, капиталь төзелеш объектларын урнаштыру планлаштырыла торган зоналар чикләрен билгеләү, территориянең планлаштырылган үсеше характеристикаларын һәм чиратлыгын билгеләү максатыннан Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Уставына таянып КАРАР БИРӘМ:

1. «Татарстан Республикасы, Лаеш муниципаль районы, Матюшино авыл җирлеге, «Наратлык» ПК, 7, 31А,10,26 йорт адресы буенча җир участоклары чикләренә кадәр газүткәргеч тармагы»территориясен планлаштыру проектын әзерләүгә керешергә.
2. Проектның эчтәлеген Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 42 маддәсенә ярашлы рәвештә билгеләргә.
3. Ачык тыңлаулар (җәмәгать фикер алышулары) үткәрүне исәпкә алып, проектны әзерләү вакытын 2023 ел ахырына кадәр билгеләргә.
4. Әлеге карар басылып чыкканнан соң ун дүрт көн эчендә физик һәм юридик затларга Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Башкарма комитетына территорияне планлаштыру проектының тәртибе, вакыты һәм эчтәлеге турында фикерләр җибәрергә тәкъдим итәргә.
5. Әлеге проектны әзерләү эшләрен оештыруны «Газпром трансгаз Казан»ҖЧҖгә йөкләргә.
6. Әлеге карарны “Кама ягы”(«Камская новь») район газетасында, Интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru. веб–адресы буенча һәм интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре Порталында урнаштырылган Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының рәсми сайтында- http://laishevo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

**Җитәкче** **А.Ә. Нурмөхәммәтов**